КУНАКЧЫЛ ТАТАРСТАН

Республикага туристларны ничек җәлеп итәргә җыеналар?

> 2

ИКЕЛӘТӘ БӘЙРӘМ

Быел 1 гыйнварда туган бәбиләр һәм әниләренең хәлен белештек

> 3

СЫНАЛГАН ЯЗМЫШ

Бәхетен очраклы рәвештә тапкан гап-гади татар хатынының тормыш хикәясе

> 4

МОҢ ПАТШАБИКӘСЕ

15 гыйнварда Әлфия Авзалованың туууына 90 ел тулды

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 6 (28973) | Сишәмбе | 17 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ШИФАНЫ КИТЕРЕП БИРӘЛӘР

РОССИЯДӘ ОНЛАЙН САТЫЛАЧАК РЕЦЕПТЛЫ ДАРУЛАР ИСЕМЛЕГЕ ТӨЗЕЛГӘН

Йөрәк авыруы, вируслы чирләр, аллергия... Тиздән әлеге чирләргә каршы кулланыла торган даруларны өйдән чыкмыйча гына да алып булачак. Бу көннәрдә Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы онлайн сатылырга мөмкин булган рецептлы дарулар исемлеген тәкъдим итте.

Даруларны өйдән чыкмыйча гына сатып алу безнең өчен яңалык түгел анысы. Моның күптән рәтенә төшендек. Үзеңә кирәкле даруны дистанцион рәвештә сатып алу бигрәк тә коронавирус котырган чорда популярлашып китте. Әйтик, әлеге зәхмәт котырган 2020 елда бу хезмәттән Татарстанда барлыгы 2,1 мең кеше файдаланган. Дөрес, әлегә Россиядә рецепт таләп ителми торган даруларны гына онлайн рәвештә сатуга рөхсәт бар. Әмма тиздән рецептлысын да даруханәгә барып тормыйча гына алып булачак. Дөрес, әлегә илнең өч төбәгендә – Мәскәүдә, Мәскәү һәм Белгород өлкәләрендә сынап караячаклар. Тәҗрибә өч ел дәвам итәчәк. Даруханәләр сынауда ихтыярый рәвештә, үз теләге белән катнаша. Тәҗрибә нәтиҗә бирсә, әлеге яңалыкны бөтен ил күләмендә кертергә җыеналар.

Рецептлы даруларны онлайн сату эше ни рәвешле башкарылачак? Әлеге тәҗрибә барышында дарулар федераль базага урнаштырылган электрон рецептлар буенча сатылачак. Анда табиблар белән даруханә хезмәткәрләре генә керә алачак. Кеше табибка мөрәҗәгать иткәндә, аңа дару алу өчен электрон рецепт рәсмиләштереләчәк. Интернет яки телефон аша үзенә кирәкле даруга заказ биргәндә, кешегә үзенең фамилиясен әйтергә кирәк булачак. Шуннан соң даруханә хезмәткәре, базадагы дару рецептын тикшереп, кирәкле даруларны курьер аша кешенең өенә җибәрәчәк. Даруны кулга тапшырыр алдыннан курьерга паспортыңны күрсәтергә кирәк. Ул, андагы мәгълүматны чагыштырып, даруларны нәкъ менә тиешле кешегә тапшыруын раслаучы документ тутырырга кушачак.

Казанның 21 номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Регина Галиуллина рецептлы даруларны да онлайн сата башлауны күптән кирәкле гамәл дип саный.

– Тормышта төрле хәлләр була. Кайчак даруханәгә чыгып, үзеңә кирәкле препаратны сатып алырга да мөмкинлегең булмый. Бала авырган вакытта бигрәк тә кыен. Өлкән яшьтәге, мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен дә иң авыр мәшәкатьләрнең берсе ул. Шуңа күрә даруларны онлайн гына сатып алу мөмкинлеге булу бик яхшы. Бу яңалык район, авыл җирлекләренә дә кертелсә, яхшы булыр иде, – ди табиб.

Мондый фикер белән Саба районының Олы Шыңар фельдшер-акушерлык пункты фельдшеры Рузилә Мөхәммәтова да килешә. Сала халкы өчен дә даруларны онлайн сатып алу мөмкинлеге булдырырга кирәк, ди ул.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Дөрес, бүген Олы Шыңар халкы даруга тилмерми анысы. Авылдагы фельдшер-акушерлык пунктының дару сатарга лицензиясе бар.

– Элегрәк бездә бөтен дару да бар иде. Киштә беркайчан да буш тормады. Дарулар бетә башлауга, яңадан алып кайтып куя идек. Хәзер даруны гариза буенча – кемгә күпме кирәк, шулкадәр күләмдә генә алып кайтабыз. Бу уңайсызрак, билгеле. Кешегә бит аңа гел бертөрле генә дару кирәкми. Бүген баш авыртканнан дару кирәк булса, иртәгә кул астында йөрәк авыртканнан даруы булмаска мөмкин. Гариза буенча гына кайтарткач, кирәк чакта гына медпунктта ул дарулар булмый. Шуңа күрә авылдагы ФАП, медпунктларда салкын тигәндә, тамак авыртканда эчә, тынычландыра торган дарулар һәрчак сатуда булырга тиеш дип саныйм, – ди Рузилә ханым.

Бу көннәрдә Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы онлайн дару сату тәҗрибәсендә катнашачак препаратлар исемлеген тәкъдим иткән. Биредә табиб язган рецепт буенча гына бирелә торган дистәләрчә дару кергән. Онлайн рәвештә сатылачак дарулар арасында барыбызга таныш – какырыкны куптара торган «Амброксол», шулай ук «Азитромицин» һәм «Амоксициллин» исемле антибиотиклар да бар. Әлеге исемлеккә эпилепсиягә, җенси көчсезлеккә, гөмбәчекләргә, ВИЧ-инфекциягә каршы эчелә торган дарулар да кертелгән. Сәламәтлек саклау министрлыгы туберкулез, деменция, яман шешкә каршы даруларны да онлайн сата башларга тәкъдим итә.

Дөрес, белгечләр бу исемлеккә кертүне кирәк тапмаган дарулар да шактый. Әйтик, составында наркотик, психотроп матдәләр булган препаратлар, иммунобиологик дарулар, составындагы этил спирты күләме 25 проценттан арткан, 15 градустан да түбәнрәк температура шартларында сакланырга тиешле дарулар онлайн дару сату тәҗрибәсендә катнашмаячак. Бу яңалык ташламалы даруларга да кагылмый. Белгечләр тәкъдим иткән дарулар исемлеге буенча фикер алышулар 27 гыйнварга кадәр дәвам итәчәк. Ахыргы исемлек 1 марттан үз көченә кереп, 2026 елның 1 мартына кадәр гамәлдә булыр, дип көтелә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Февральдән ала башлыйлар

Татарстанда кайбер медицина хезмәткәрләре махсус социаль түләү ала башлаячак. Аны республика Социаль фонды февраль аеннан бирә. Әмма башта сәламәтлек саклау оешмалары мондый ярдәмгә хокуклы белгечләрнең исемлекләрен төзергә тиеш.

Шулай итеп, сырхауханәләр, район үзәк һәм участок хастаханәләре, шулай ук «Ашыгыч ярдәм» хезмәткәрләренә шундый түләү билгеләнә. Аның күләме белгечнең категориясенә һәм медицина оешмасы төренә бәйле рәвештә 4,5 мең сумнан 18,5 мең сумга кадәр булачак.

Россия Социаль фондының Татарстан буенча башлыгы Эдуард Вафин әйтүенчә, социаль түләүне алу өчен гариза язып тапшырырга кирәкми. Акча автомат рәвештә күчәчәк. Медицина оешмасы, үз хезмәткәрләре исемлеген төзеп, Социаль фондка тапшырганнан соң, җиде эш көне эчендә акча түләнеләчәк. Гыйнвар ае өчен исәпләнгән түләүге пособиеләр февраль азагында күчереләчәк.

Полина җавап бирә

Суд приставлары хезмәте дистанцион хезмәт күрсәтә башлаган. Татарстанда яшәүчеләр хәзер үзләренең бурычын виртуаль ярдәмче Полина аша гына да белә ала. Хезмәтнең республика буенча идарәсе матбугат хезмәте хәбәренә караганда, робот шалтыратучының фамилиясен, исемен, атасының исемен, туу датасын, кайсы төбәктә теркәлеп яшәвен сорый. Шуннан соң мәгълүматлар базасына кереп, тиешенчә җавап бирә.

Робот киңәйтелгән мәгълүмат белән дә таныштыра. Әмма моның өчен ИНН яки СНИЛС мәгълүматлары да кирәк. Шулай итеп, Полина (8 800 303-00-00) аша бурычны түләтү турында эш кузгату, милеккә, банк счетына арест салу, милекне теркәүгә бәйле чикләүләр салу, Россиядән чыгуны чикләү, бурычны түләү өчен акча хәрәкәте һәм реквизитлар турында мәгълүматлар алырга мөмкин.

Эт асрауның яңа тәртибе

Татарстанда эт-мәче асрауга һәм аларны урамда йөртүгә карата өстәмә таләпләр кертергә җыеналар. Министрлар Кабинетының Ветеринария баш идарәсе бу җәһәттән тиешле карар проекты әзерләгән. Документ Хөкүмәт порталында басылып чыккан.

Таләпләр буенча, берничә гаиләне үзенә сыендырган коммуналь фатирда яки торакта йорт хайванын барлык милекчеләрнең язмача ризалыгы белән генә асрарга мөмкин. Этне бары тик койма белән тотып алынган урында – ишегалды яки бакчада гына бәйсез йөртү рөхсәт ителә. Шул ук вакытта ишеккә, эт барлыгын кисәтеп, тиешле язу урнаштырырга кирәк булачак.

Маэмайны урамда йөртүгә килгәндә, берничә яңа кагыйдә кертелә. Әйтик, аны «һава сулау» урынына муенчак белән, борынчык кидертеп алып килергә кирәк. Әмма кагыйдәдән чыгармалар да бар. Мәсәлән, кәрлә токымлы этне, 3 айга кадәрге көчекне урамга күтәреп яки кәрҗингә утыртып алып чыккан очракта, муенчак та, борынчык та кирәкми.

Исерекләргә урамда эт белән йөрү тыела. 14 яшькә җитмәгән балалар да аларны (3 яшькә кадәрге көчек һәм кәрлә токымлы этләрдән тыш) үзләре генә урамда йөртә алмый.

Мөнәсәбәт

Өйләнү түгел сөйләнү

ТАТАРСТАН ГАИЛӘ КОРУЧЫЛАР САНЫ БУЕНЧА АЛДЫНГЫЛЫКНЫ САКЛЫЙ

«Өметкә өйләнәләр, вәгъдәгә кияүгә чыгалар» дигән мәзәк бар халыкта. Хаклык та юк түгел инде. Гаилә корганда иң яхшы пар булырбыз дип вәгъдәләр бирәсең, күктән йолдызлар алып бирерләр дип тә өметләнәсең бит. Яхшы мәгънәдә әйтәбез инде. Татарстанда да андыйлар күп бугай – Росстатның статистикасы шул хакта сөйли.

Саннарда да – кеше язмышлары

Татарстанда яшәүчеләрнең гаилә хәле ничегрәк? Росстат узган елга нәтиҗә ясап, шул хакта мәгълүмат белән уртаклашты.

Татарстан 2022 елның гыйнвар – ноябрь айларында Идел буе федераль округы төбәкләре арасында гаилә коручылар саны буенча алдынгылар арасында булды. Республикада бу коэффициент 7,2 тәшкил иткән. Татарстаннан алдарак – Пермь крае. Аларда әлеге күрсәткеч – 7,3. 2021 елның шушы ук чорында әлеге коэффициент түбәнрәк иде – 6,4. Шулай да республика лидерлыктан төшмәде.

Быел бездән астарак исә Самара өлкәсе (7,1). Күңелсез статистика Мари Иле, Чувашия һәм Мордовиядә күзәтелә. Анда никахлашучылар коэффициенты 5,3 кенә икән. Шул ук вакытта Идел буе федераль округы субъектлары арасында уртача күрсәткеч 6,6га тигез.

Сан телен дәвам итсәк, былтыр Татарстанда 25476 никах теркәлгән. Аннан азрак күрсәткеч күршеләрдә: Башкортстанда гаилә коручылар – 23277. Мари Илендә тормыш

сукмагыннан бергә атларга карар кылучылар 3274 кенә. Бу – субъектлар арасындагы иң аз күрсәткеч тә.

Әмма сөенеч янында көенерлек сәбәп тә бар. 2022 елның гыйнвар – ноябрь айларында Татарстанда 13327 пар аерылышкан. Мисал өчен, ноябрь аенда былтыр 1304 парның мөнәсәбәтләренә нокта куелган. Шулай да, былтыргы чорның саннары белән чагыштырганда, аерылышучылар саны 2,4 процентка кимеде дип тынычландыралар. Бу җәһәттән республика Идел буе федераль округындагы төбәкләр арасында икенче урынны били.

> Беренче урында – Башкортстан. Бу чор эчендә биредә 15918 аерылышу очрагы теркәлгән. Гомумән, 11 ай эчендә Идел буе федераль округында 110563 пар аерылышкан. Аларның саны узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 0,9 процентка арткан.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Илдар ГАБДРАФИКОВ, этнолог:

Җанисәп буенча ашыгыч нәтиҗә ясарга, кемнеләр гаепләргә ярамый. Башта төбенә төшеп анализларга кирәк. Шуннан соң гына татарлар һәм Россиядәге башка халыкларның алга таба да саны кимемәсен өчен чаралар күрергә була.

(«Миллиард.Татар»га әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – ИНВАЛИДЛЫК

Ел башында республикада физик мөмкинлеге чикле 286,4 мең кеше теркәлгән. Бу – барлык халыкның 7,4 проценты.



Эш эзлиләр

Россиядә бүген бер миллион ярым чамасы кеше яңа эш урыны эзли, хатын-кызлар ир-атларга караганда күбрәк. HeadHunter эш эзләү сервисының сораштыру нәтиҗәләре шундый.

Сораштыруда катнашучыларның 49 проценты актив төстә эш эзләүләрен күрсәткән. 31 проценты, эшләсә дә, яңа тәкъдим кабул итәргә әзер. 2 процентына инде яңа хезмәт урыны тәкъдим ителгән. 11 проценты эш эзләү буенча әлегә бернинди дә нәтиҗәгә ирешмәгән.

Сату буенча менеджерлар (9%), администратор (6%), машина йөртүчеләр, сатучы, кассир, хисапчы һәм проект җитәкчеләре (барысы да – 4әр процент), шулай ук секретарь, программистлар (өчәр процент) эшне башка һөнәр ияләренә караганда ешрак алыштыра икән. Яңа эш табарга теләүчеләр Мәскәүдә (28%), Санкт-Петербург (11%), Мәскәү өлкәсе (6%), Краснодар крае (4%), Свердловск өлкәсендә (3%) барыннан да күбрәк теркәлгән.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

САГЫШЛЫ ДАТА

Үткән атнада бөтендөнья тарихына зур борылыш булып кергән вакыйга – Кытайда COVID-19 нәтиҗәсендә рәсми рәвештә теркәлгән беренче үлем очрагына 3 ел тулды. 2020 елның 15 гыйнварында әле без үзебезне нинди турбулентлык көтүен белмәдек, коронавирус турындагы беренче хәбәрләрне күпчелек ышанмыйча һәм елмаеп кабул итә иде. Өч ел эчендә 654 миллион авыру очрагы теркәлде, 6,5 миллион кеше үлде, ди рәсми саннар. Чынлыкта, чир кагылып үтмәгән беркем дә калмады диярлек. Статистика бары тик табибларга мөрәҗәгать итеп, авыруы рәсми рәвештә теркәлүчеләрне генә саный. Пандемия икътисадта зур үзгәрешләр китереп чыгарды: дәүләтләр арасында товар алмашу һәм хезмәттәшлек тукталды диярлек, чимал бәяләре башта кискен түбәнгә киттеләр, аннан соң рекордлы үсеш башланды. Дәүләтләр, социаль яклау чаралары оештырабыз дип, чамасыз күп акча бастылар, инфляция котырынды. Изоляция – кешеләрнең өйгә бикләнүе, куар-кодлар ярдәмендә массаларны тоталь контрольгә алу омтылышы көн тәртибенә басты – цифрлы коллыкның беренче элементлары мәйданга чыкты, мәҗбүри вакциналаштыру кешеләрнең үзәгенә үтте. Болар барысы да зур канәгатьсезлек, планетакүләм каршылык хәрәкәте тудырды. Европада, Төньяк Америкада массалар урамнарга чыктылар. Бары тик Россиядә генә мәйданнар тын иде. Кытайда аеруча каты кыландылар: миллионлаган кеше яшәгән шәһәрләр бикләнделәр, урамнарга чыгу тыелды, адым саен тест тапшырырга туры килә башлады.

Пандемиягә каршы көрәш тоталитаризмның дилбегәне бик тиз үз кулына алырга әзер торуын күрсәтте. Кызыгы шунда: тоталитар дәүләтләр (Кытайны исәпкә алмаганда) коронавирус белән көрәшне алай катгый яссылыкка салмадылар, аларда чагыштырмача хөрлек хөкем сөрде. Көнбатыш демократияләре исә үзләрен акылдан язган кебек тоттылар: вакциналаштыру ешлыгы өч айга кала башлады, өченче, дүртенче тапкыр прививка ясату кайбер илләрдә массакүләм төс алды. Нәтиҗәләр якынча бертөрле диярлек булды: чикләүләр кертмәгән һәм вакциналаштыруны катгый таләп итеп куймаган илләр белән тоталь көрәш сукмагына чыккан дәүләтләрдә чир таралу һәм үлемнәр статистикасында зур аермалар күзәтелмәде. Нуль – ковид сәясәте алып барган Кытай, халык басымы астында чикләүләрне бетергәннән соң, без өч елда үткән юлны өч атнада үтәргә мәҗбүр булды. Чирнең кинәт һәм кискен таралуы нәтиҗәсендә алар хәзер массакүләм берьюлы чирлиләр. Пандемия тагын бер тапкыр Лыковлар гаиләсе феноменының хаклыгын раслады. Себердә изоляция шартларында яшәгән староверлар гаиләсе, цивилизация белән контактка керүгә, ОРЗ һәм пневмониядән чирләп үлеп беттеләр диярлек, чөнки алар тәнендә бездә булган антитәнчекләр формалашмаган иде.

COVID-19га каршы көрәш ничек кискен башланган булса, шулай туктады да. Коронавирус безнең арада йөри һаман да, яңа вариантлары да чыгып тора, әмма табигый рәвештә формалашкан иммунитет нәтиҗәсендә без аннан алай ук курыкмыйбыз инде. Үткән көрәшнең уңай һәм тискәре сабаклары өйрәнелә торгандыр, һәм яңа пандемия тарала калса, искә алыныр дип уйлыйк.

Россиядә

РОССИЯНЕҢ ИКЕ СЫЗЛАВЫГЫ

Пандемияле чорны Россия чагыштырмача тыныч үтте. Бездә COVID-19га каршы көрәштә уртачылрак юл сайланды: изоляция булды, әмма озакка түгел, вакциналаштыру булды, ләкин алай ук катгый түгел. Без прививкалауның беренче әйләнешен дә үтеп бетерергә өлгерә алмадык: вакциналаштыру процентлары Көнбатыштагыдан түбән иде, тик моннан бер дә зарланмыйбыз. Бүген безне бөтенләй башка проблемалар борчый. Көнбатыш чикләрдәге конфликт үзәккә үтә һәм шуңа бәйле санкцияләр басымы иңне изә.

Көнбатыш чикләрдә исә хәлләр киеренке кала. НАТО альянсы һөҗүм итү өчен кирәкле авыр техниканы Украинага китерү мәсьәләсен хәл итәргә азаплана. «Российская газета» җиңел француз танкларын китерү мәсьәләсе хәл ителүен язды инде. Берничә ил Leopard танкларын китерү проблемасы өстендә баш вата. Германиядә җитештерелгән ул танкларны немецлар рөхсәтеннән башка биреп булмый. Германиягә шул максаттан көчле басым ясала, әмма Берлин, өздереп, бер сүз дә әйтмәде әле. Гадәттән тыш авыр инглиз танкларын (Украинада аларны файдалану кыен, чөнки аларны чыдатырлык күперләр юк) ун данә китерәчәкләре игълан ителде инде. Россия өчен болары артык зур проблема түгел, бердән, танклар саны аз, икенчедән, аларны кулланырга өйрәнү өчен байтак вакыт таләп ителә. Французлар, әйтик, үз танкларын ике айдан соң гына китереп җиткерәчәкләрен белдерде. Украина конфликты Россиянең зур коалициядән торган дәүләтләр союзы (НАТО гына түгел, башка дәүләтләрне дә кушып) белән бәрелешенә әверелү ихтималлыгы белән куркыныч. 15 гыйнвар көнне Америка телевидениесе, НАТОның көнчыгыш флангын ныгыту өчен, Нидерландтагы Флиссинген портына зур санда танклар һәм хәрби техника китерелүен хәбәр итте. «Портка 1250 данә хәрби техника китерелә», – диде зәңгәр экран аша Америка полковнигы Роберт Келлам. Болар – Польша һәм Литвада урнашачак көчләр. Ул илләрдә НАТО хәрбиләре болай да күп инде.

Икенче сызлавык – нефть продуктларын сатуның Россия өчен зур проблемага әверелүе. Европа илләре Россиядән китерелгән дизель ягулыгы һәм мазуттан баш тартты. Эмбарго 5 февральдән үз көченә керә. Әмма Көнбатышта моның белән генә чикләнмиләр. Нефть продуктларына да нефтьнеке кебек үк «түшәм» бәя куярга телиләр. Дизель ягулыгына – аерым, мазутка аерым бәя булыр дип көтелә. Бу, шиксез, Россия өчен матди югалтуларга әйләнәчәк. Energy Aspects Ltd. компаниясе белгечләре Россия дизель ягулыгы экспортының өчтән беренә генә урын табачак, калганын җитештерүне киметү белән генә хәл итеп булыр, диләр. Мазут турында беркем дә бер сүз әйтми. Дизель ягулыгына караганда анысы зуррак проблема тудырачак. Мәскәүдә бу хакта беләләр һәм чишелеш эзли торганнардыр инде.

КИЛДЕ ДӘ КИТТЕ ТҮГЕЛ…

Нәтиҗә

2022 елда Татарстанга ничә кунак килгән? Мәдәни мирас өлкәсендә нинди яңалыклар бар? Татарстанның Туристлык буенча һәм Мәдәни мирас объектларын саклау буенча дәүләт комитетлары йомгаклау коллегиясен бергә уздырды. 2022 елда ниләр эшләнгән һәм яңа елга нинди ниятләр белән керәләр – әнә шул турыда сөйләштеләр.

Татарстанда туризм өлкәсен мәдәни мирас объектларыннан башка күз алдына китереп булмый. Россиянең икътисадый үсеш министры урынбасары Дмитрий Курков ике комитетның бергә эшләвенең уңай нәтиҗәләргә китерүен искәртте.

– Татарстанда туризмны үстерү һәм мәдәни мирасны саклау мәсьәләләре бергә хәл ителә, бу исә республикага әлеге өлкәләрдә уңышка ирешергә мөмкинлек бирә. Моннан тыш, Татарстан бу юнәлешләр өчен һәм, гомумән, икътисад үсеше өчен ресурслар җәлеп итү һәм куллану буенча алдынгы төбәкләрнең берсе булып тора. Аерым алганда, соңгы өч елда республикага туризмны үстерү өчен 1 миллиард сумнан артык акча бүлеп бирелде. Шуның 681 миллионы – федераль бюджет акчасы. Ә нәтиҗәләргә килгәндә, Татарстан – төрле күрсәткечләр буенча алдынгы урыннарда. Республикадагы туристлар агымы елдан-ел арта. Әйтик, 2021 ел белән чагыштырганда, узган ел бу сан 12 процентка арткан, – дип сөйләде ул.

Мирас сагында

Татарстанның Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Гущин, 2022 елга нәтиҗә ясап, кайбер санлы мәгълүматлар белән таныштырды, киләсе елга бурычлар куйды. Ул шулай ук КФУның Энгельгардт исемендәге астрономик обсерваториясенең ЮНЕСКОның беренчел исемлегенә кертелүенә дә аерым тукталды.

Мәгълүм булганча, хәзерге вакытта республика территориясендә Россия халыкларының мәдәни мирас объектларының бердәм дәүләт реестрына кертелгән 1714 шундый объект исәпләнә. Шуның 447се федераль әһәмияткә ия. Барлыгы 205 объектка исә реставрация таләп ителә.

– Реставрация эшләре 2022 елда да тынып тормады. Комитет өчен «Дротоевский йорты»ндагы эшләрнең төгәлләнүе аеруча мөһим. Бурычларга килгәндә, быел Кама Тамагы районындагы Михаил Архангел чиркәвендә эшләрне тәмамларга ниятлибез. Ә Казандагы Завод мәчетендә, Әтнә районындагы «Даутов йорты»нда, Биектау районының Айбаш авылы мәчетендә реставрация эшләре дәвам итәчәк, – дип сөйләде комитет рәисе.

Иван Гущин сүзләренчә, 2023 елда 177 мәдәни мирас һәм 259 архитектура объекты территориясенең чикләрен билгеләү буенча эш алып барылачак.

Йомгаклау коллегиясендә Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә катнашты. Үз чыгышында ул тарихи мирас объектларын саклау һәм торгызуны бөек эш дип атады.

– Күпмилләтле халкыбызның тарихи мирасын торгызу эшен алып барганда, без, асылда, үзебез яңарыш кичерәбез. Бу – укымышлы, мәгърифәтле кешеләр юлы. Моны аңлаган халкыбызга рәхмәт. Без мирасыбызны үзебездән соң киләчәк буынга тапшырырга әзер. Хәзер бары тик бу эшне башкару юлларын гына камилләштерергә кирәк. Беләм, без моны да булдырачакбыз, – диде ул.

Кунак булсаң…

Мәдәни мирас объектларыннан кешеләргә кучсәк, Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Иванов фаразлаганча, 2022 елда республикага 3,7 млн турист килгән булырга тиеш. Әлегә төгәл сан юк, бары фараз гына. Шулай булуына карамастан, 2021 ел белән чагыштырганда, безгә килгән туристлар саны шактый арткан. Бу үсеш 12 процент дип бәяләнде. Иң күп кунаклар Башкортстан, Удмуртия һәм Мәскәүдән килгән.

Татарстанга килгән кунакларның күпчелегенең республикага гашыйк булып кайтып китүе гаҗәп хәл түгел, билгеле. Республиканың туризм өлкәсе үсә, үзгәрә. Моны Сергей Иванов санлы күрсәткечләр белән дә, аерым мисаллар белән дә раслады. Шуннан соң ул туризм өлкәсендәге проблемаларны санады. Аларны Татарстанга килгән туристлар үзләре атаган.

– Беренчедән, хезмәт күрсәтү өлкәсенең аксавы. Икенчедән, елга транспорты өлкәсенең камил булмавы. Өченчедән, туристлар өчен автобуслар җитмәү. Дүртенчедән, кунакханәләрнең җитәрлек булмавы. Бишенчедән, туристлар агымы зур булган чорда эшчеләр җитмәү. Шушы проблемалардан чыгып, бурычлар билгеләнде, һәм аларны хәл итмичә, туризм тармагын үстерү мөмкин булмаячак, – диде комитет рәисе.

Президент Рөстәм Миңнеханов та йомгаклау коллегиясендәге чыгышын ике комитетның «йомшак» урыннарын барлаудан башлады.

– Без үзебезне мактарга яратабыз инде. Ләкин проблемаларыбыз да җитәрлек. Аларның барысын да комитет рәисләре үз чыгышларында җиткерде. Әмма алар коллегиядә генә хәл ителми. Һәр сорауны аерым карарга кирәк, – диде ул. – Бүген сез дини үзәкләрне телгә алмадыгыз. Алар шулай ук игътибар үзәгендә булырга тиеш. Дини үзәкләрдәге инфраструктураны камилләштерергә кирәк. Алар үзенә күрә тарту ноктасы булырга тиеш. Мәдәни объектлар да һәйкәл ролен үтәргә түгел, ә Татарстан халкына һәм кунакларыбызга хезмәт итәргә тиеш, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КУРКЫНЫЧ ТЕЛЕФОН

«Балаларга ялган газчылар шалтыратып, өйгә ис чыксын өчен, газ җиһазларын ачып куярга кушалар...» Бу елларда социаль челтәрләр әнә шундый эчтәлектәге хәбәрләр белән тулды. Соңрак моның интернетта инде берничә елдан бирле йөргән ялган мәгълүмат булуы да ачыкланды. Тик әти-әниләрдә шик калды. Бала кулыннан телефон төшмәгән бүгенге заманда куркырсың да...

Заманасына күрә – чире дигәндәй, соңгы арада телефон мошенниклары саны бермә-бер артты. Алдауның да нинди генә юлын уйлап тапмыйлар. Юл һәлакәтенә эләккән бала исеменнән дә, паспорт күчермәсе буенча зур суммада кредит рәсмиләштерергә теләүчеләрдән котылырга ярдәм итүче банк хезмәткәре булып та, мобилизациягә эләгүчеләр исемлегеннән сызып ташларга вәгъдә итеп тә шалтыраталар хәтта.

Ял көннәрендә социаль челтәрләрдә ялган газчылар турында таралган мәгълүмат та шактый шаушу тудырды. Анда үзен газ оешмасыннан дип таныштырган хатын-кызның, балага шалтыратып, аның өйдә үзе генә булуын ачыклавы һәм, ис чыксын өчен, газ җиһазларын ачарга кушуы турында әйтелә. Телефоннан сөйләшүче кыз бала: «Әнигә шалтыратам», – дип тә әйтеп карый. Тик телефон мошенниги моны эшләмәскә үгетләп, өйдә ис чыгып торган килеш, балага күрше бүлмәдә бер-ике сәгать ял итәргә куша. Интернетны «басып алган» әлеге хәбәрдән соң, «Газпром Трансгаз Казан» оешмасына аңлатма бирергә туры килде хәтта. Белгечләр әйтүенчә, газ хезмәте оешмасы хезмәткәрләре беркайчан да кулланучыларга телефоннан шалтыратып, тегене-моны эшләгез дип өйрәтми. Газ белән саксыз эш итү фаҗигагә китерергә мөмкин дип тә кисәттеләр.

Интернетта таралган ялган хәбәрнең чыбык очы исә 2018 елга ук барып тоташа булып чыкты. Илнең төрле төбәкләрендә ялган газчылар турында моннан дүрт ел элек үк хәбәр иткән булганнар. Чират Казанга да килеп җиткән, күрәсең. Бу елларда шундый ук эчтәлектәге хәбәрләр Чиләбе өлкәсендә, Приморье краенда да теркәлгән.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәтеннән әйтүләренчә, хокук сакчыларына мондый очрак турында хәбәр килмәгән. Алай да, уяулыкны югалтырга ярамый. Бигрәк тә сүз балалар турында барганда. Озак еллар полициянең участок вәкиле булып эшләгән Андрей Смирнов сүзләренә караганда, телгән очракта, балаларның телефон номерларын социаль челтәрләр аша эзләп табарга мөмкиннәр. Анда аларның яше дә күрсәтелгән. «Таныш булмаган кешеләр белән сөйләшмәскә, аларга ишек ачмаска һәм ят машинага утырмаска – боларны һәр бала кечкенәдән үк белергә тиеш», – ди Андрей Смирнов.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, мәктәпләрдә балаларны куркынычсызлык кагыйдәләренә өйрәтү эше даими рәвештә алып барыла. «Тормыш иминлеге нигезләре дәресе кысасында янгын сүндерүчеләр белән дә, полиция вәкилләре белән дә очрашулар үткәрелә, аңлату эшләре оештырыла», – диделәр министрлыкның матбугат хезмәтеннән. Әти-әниләрнең җаваплылыгы турында да искәрттеләр.

Татарстанның Әтиләр берлеге рәисе Гадел Заһретдинов әйтүенчә, бүген үсмерләрнең кирәксә-кирәкмәсә дә телефонны кулдан төшермәве борчыган мәсьәлә булып тора.

– Телефон, интернет тере аралашуны да алмаштырды хәтта. Сер түгел, балалар күбрәк вакытын онлайн үткәрә. Тәрбия өйдә башлана, шул исәптән интернеттан дөрес файдалануга кагылышлысы да. Әти-әниләр баланың интернеттагы чикләрен кысмыйча, онлайн дөньяны контрольдә тота белергә тиеш. Ә иң яхшысы – шәхси үрнәк. Балалар барысына да бездән күреп өйрәнә. Әнә шуны истә тотарга кирәк, – ди Әтиләр берлеге рәисе.

Балалар психологы Гүзәл Садыйкова фикеренчә, мәктәп яшендәге балаларның өйдә телефонга «чумып» утыруына акырынып-бакырынып йөрүдән файда юк.

– Гаджетлар уку өчен булса да кирәк. Әнә пандемия вакытында балаларны үзебез үк компьютер, телефон каршына утырттык бит. Ә хәзер кире тартып алабызмы? Иң мөһиме, интернеттан агылган мәгълүматтан дөрес итеп файдалана белү зарур. Баланың шул ук «YouTube»та, мәсәлән, нәрсәләр белән кызыксынуына игътибар итегез. Интернеттан нинди куркыныч янавы турында сөйләшегез. Әти-әниләр өчен баланың кесә телефонында теге яки бу сайтка керүне чикләүче махсус кушымталар да бар, – ди психолог. – Статистика мәгълүматларына караганда, бүген 3–6 яшьлек балаларның 42 процентының үз кесә телефоны бар, шуңа күрә тәрбияне төрле гаджетлардан башка күз алдына да китереп булмый. Тик төсләрне аерырга, санарга өйрәтәм дип, сабыйга кесә телефоны биргән әти-әниләр нык ялгыша. Чөнки гаджетлар тәрбияләми, алар баланы кече яшьтән үк билгеле бер программага кора. Мәсәлән, шакмакның шакмак икәнен аңлау өчен, аны тотып карарга, төрле яклап боргаларга, тәгәрәтеп уйнарга кирәк. Ә телефон нишли? Ул бары тик үзенә кирәкле җавап бирүне таләп итә, ягъни бала тиешле төймәгә басарга тиеш.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ИРЛЕ-ХАТЫНЛЫ СЫЕР САВУЧЫЛАР:

«ШӘҺӘР КЕШЕСЕН ДӘ АШАТЫРГА КИРӘК БИТ»

Икесенә – 120 сыер. Питрәч районының Шәле авылында яшәүче ирле-хатынлы Алинә белән Алексей икесе дә фермада сыер сава. Алар кайда гына эшләп карамаган, әмма монысы күңелләренә иң якыны икән. Алинә үзенең атказанган сыер савучы булырга теләвен дә яшерми. «Миңа әле чират җитмәгәндер», – ди. Алексей да, бу бит – хатын-кыз эше, дип сайлана торганнардан түгел. Эш һәм аш дип яши алар.

12 яшьтән үк сыер җиленен тарта башлый инде Алинә. Әнисенә ияреп, фермага сыер саварга йөргән. Әбисе дә, әнисе дә, апалары да сыер савучылар икән. Тугызынчыда укыганда, ул да фермага барып урнаша. Дөрес, хәзер яхшылап укымаганы, мәктәпне тәмамламаганы өчен үкенеп тә куя. «Алма агачыннан ерак төшми. Бөтенебез дә түрә, «ак яка» гына булып бетә алмый. Шәһәр кешесен дә ашатырга кирәк бит, – ди 42 яшьлек Алинә Хәйруллина. – 1995 елда әни сәламәтлеге какшау аркасында ялга чыкты да, декабрь аенда аның урынына тизрәк эшкә урнашу ягын карадым. Җитешмәгән тормыш та үзенекен итте. Без гаиләдә – өч бала, мин – иң олысы. Әтиәниләрем мәрхүм инде».

Баштарак көнгә 20шәр сыер сауса, хәзер бу сан өч мәртәбә күбрәк. Бер сыерга – 30 литр, барлыгы ике тонна сөт дигән сүз бу. Алинә әйтүенчә, үткән белән чагыштырганда, эшләре күпкә җиңеләйгән. Сенажны тракторга төяп, сәнәк белән малларга ташу да, авыр чиләк күтәреп йөрү дә юк. Иртүк берәр сәгать сыерларны кыргыч белән чистарталар, аннан савып, аппаратларын юалар. Эш тәртибе шундыйрак. Анда мал-туардан курыкмый ул. Сыерларга «кызым» дип дәшә. Сава башлаганчы, акыллы бит сез, дип башларыннан сыйпый.

– Сыерның сөте – телендә, диләр. Алдында һәрвакыт азык, тәмле әйбер торсын. Замана сыерларына витаминга бай ризыклар гына бирәбез. Ашаткач, сөте дә бар, – ди ул.

Дөрес, сыерлар янынннан китеп торган вакытлары да булган. Хезмәт хакы түләмәгәч, Алинә, шәһәргә барып, идән дә юган, кафеда да эшләп кайткан. Базарга барып, каймак, эремчек тә саткан. Тик барыбер күңеле фермага тарткан аның. Бу эшен бернәрсәгә дә алыштырасы килми. Акчасын гына түләп торсыннар, ди. Хәзер кулына ай саен 40 мең сум керә икән. Ире Алексей да аннан ким алмый. Алинәне фермада бригадир дип йөртәләр. Берәр нәрсә хәл итәсе булса, киңәшен сорыйлар һәм аның әйткән сүзе еш кына дөрес булып чыга икән.

Алинә эштә генә түгел, гаиләдә дә бәхетле хәзер. Зур сынаулардан соң очраткан ул Алешасын.

– Беренче иремә яратмыйча гына кияүгә чыктым. Икенчесендә урладылар. Авылда шундый гадәт бар. Бик ошатып барсам да, эчкән кешене туктатып булмый шул. Ә Леша миннән 10 яшькә яшьрәк. Аның белән никах укыттык, тугыз ел яшибез инде. Бер-беребезгә «матурым» дип дәшәбез. Ачуланышкан чаклар юк, шөкер. Бер-беребезгә юл куя беләбез чөнки. Тормыш итәргә бик әйбәт. Хатын-кыз эше дип тормый, табак-савытын да юарга булыша. Улым Айсафны үзенеке кебек күрә, – дип сөенә Алинә.

Алексей – чуаш милләтеннән. Авылга килгәндә, бер кәлимә татарча сүз белмәсә дә, хәзер барысын да уздыра. Авылга «шабашка»га эшкә килгән Алексей, Алинәне күргәч, Шәледә калган. Бергәләшеп сыер савалар. Хәзер инде 12 ел стажы бар егетнең. Иртән сәгать бишенче яртыда торып, бергә эшкә китәләр, парлашып өйгә кайтып керәләр. Бергә булу туйдырмый, диләр. Алексей күп сөйләшергә яратмый. Без килгәндә, йорт тирәсендә кайнаша иде. Фермадагы бөтен сыерның биографиясен, гадәтләрен белә икән.

Тормышлары җитеш инде хәзер. Тик акчаның һаман җитәсе юк. Алинәнең улының гаиләсенә дә булышасы килә. Алар Казанда яши. Сеңелләрен дә ташлап бетерәсе килми. Шуңа күрә башында гел эш кенә икән.

– Үзебезне яратмау бер дә дөрес түгел инде. Бизәнеп-ясанып тормыйм, ислемаемны сибәм дә эшкә китәм. Ялны онытабыз шул. Отпускыда да – фермада. Ике ай декрет ялында утырдым, шуннан бирле ял күргән юк. 27 ел эчендә бер ай больничныйда булдым. Аягыма сыер басмаса, анысы да эләкмәс иде. Тагын әле 42 яшькә бер тапкыр өч көнгә Мәскәүгә барып кайттым, – дип елмая ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шәледән чыкканы юк дигәч тә, бөтенләй алай ук түгел. Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре бәйрәмендә Казанга Президент белән очрашуга барган ул. Мактау кәгазьләре дә җитәрлек. Сөт саву аппаратын сүтеп җыю ярышларында беренче урын алган чаклары да бар. «Мин – гомерлек сыер савучы», – дигән Алинә моның белән туктарга җыенмый. Атказанган исемен алмыйча эшен ташларга исәбе юк. 60та буламы ул, 70тәме…

Сәрия МИФТАХОВА

Өйләнү түгел сөйләнү

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Гомерлек булсын

Практик психолог Зөһрә Кәримованы гаилә коручыларның саны артуы гаҗәпкә калдырган. Хәер, яшерми: психологик сеансларга килүчеләрнең күбесе «гаилә корырга телим», «кияүгә чыгасым килә» кебек сораулар белән мөрәҗәгать итә икән.

– Гаилә коручыларның артуына берничә сәбәп бар дип әйтә алам. Беренчедән, гүзәл затларга кемгәдер кирәк булу, ир-ат җилкәсен, ир-ат яклавын тою мөһим. Курку-борчылу хисләре дә кешене мондый карарга килергә мәҗбүр итә. Икенче сәбәп итеп мобилизация шаукымын әйтергә мөмкин. Иртәгә ни буласын берәү дә төгәл белми. Шуңа да ялгыз калу куркыта. Күпләр моны сәбәп итеп өйләнә яисә кияүгә чыга дип әйтергә нигез бар, – дип аңлата белгеч. – Тагын бер сәбәп – җәмгыять фикере. Ягъни «синең яшьтә инде…» дигән калыплашкан сүз тәэсире. Имеш, фәлән яшьтә инде гаиләле булу, балалар табу тиешле. Шуңа карап тискәре статистика да күзәтелә бит: аерылышучылар саны да байтак. Бу да борчымый түгел.

Өйләнешүчеләр бар, дип җиңел суласак та, гаилә корырга теләп тә, бу юлда мең дә бер киртә күрүчеләр дә юк түгел. Әйтик, Казан кызы Раилә Хәйретдинова, тиң ярын тапса да, кияүгә чыгарга ашыкмый.

– Узган елның декабрь аенда егетем тәкъдим ясады. Башка кызларны, дус-ишләремне күргәнем бар бит инде: сөенәләр, шундук бу хәбәр белән социаль челтәрләрдә уртаклашалар. Мин социаль челтәрләргә кую түгел, әти-әниемә бу яңалыкны ничек әйтергә дә белми аптырадым. Тәкъдим ясаган мизгелдә шок хәлендә идем, – ди ул. – Сүз дә юк, мин сайлап алган ярымны яратам, аның белән булырга телим. Әмма тәкъдим ясауның эйфориясеннән битәр, алда көтеләчәк мәшәкатьләр күз алдыма килеп баса да, төшенкелеккә бирелəм. Гаилә корыр өчен иң элек күңел тынычлыгы һәм ил-көндә иминлек кирәк. Миндә болар юк. Иртәгә ни буласын белмим. Шуңа икеләнәм дә. Аннан, күп кызлар, тәкъдим ясалгач та, никах-туй чыгымын кем күтәрәсен уйламый ич. Әти-әни җилкәсенә төшә ул, йә булмаса – кредит. Мин алай булуын теләмим.

Фикер

Рөстәм хәзрәт ЯСӘВИЕВ, «Рәхмәтулла» мәчете имам-хатыйбы:

– Кызларның, кияүгә чыкканда, иренә, фатирың булсын, машинаң булсын, дип шарт куюы гаҗәп түгел. Ул гаиләсенең киләчәге турында кайгырта дип аңларга кирәк. Һәрхәлдә, тормыш корырга теләгән егет кулында мал-мөлкәт булырга тиеш. Юк икән инде, теләге булсын. Теләге булса, 2–3 ел тырышып эшләсә, башлы-күзле булырлык кына мал туплап була. Ирләр дә үзләренә хатын сайлаганда аның буена, йөзенә генә күз салмасын иде. Иң мөһиме – балаларына дөрес тәрбия бирә алучы ана булуы. Ир-ат өйләнер алдыннан янындагы ярына карап: «Ул минем балаларымны дөрес итеп тәрбияли алырмы?» – дип үзеннән сорарга тиеш.

Шуңа да гаилә корганчы, мәҗлес үткәргәнче мая туплау яклы идем. Хәзер инде туйга әзерлек бара.

Шулай, җәмәгать. Тукай белми әйтмәгән инде ул, өйләнү түгел сөйләнү дип. Өтерен дә төрле кеше төрле урынга куя бит әнә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сөенеч

БЕРЕНЧЕЛӘР

19 кыз, 11 малай! Быел 1 гыйнварда республикада барлыгы 30 сабый дөньяга аваз салган. Әйтик, Казанда яшәүче Шәфигуллиннарның уллары Әскәр Яңа елның беренче минутында туган. 2023 елның беренче бәләкәчләре арасында Давыд, Дамир, Әскәр, Элита исемле сабыйлар бар. Без әниләр һәм бәбиләрнең хәлен белештек.

Гөлназ Шәфигуллинаны (рәсемдә) бала тудыру йортына ире Яңа ел табынына утыргач алып киткән. Әскәр – аларның беренче сабыйлары. Гаилә башлыгы Фаилнең хыялы чынга ашкан. 2021 елның 31 декабрендә булачак хатынына тәкъдим ясаганда, киләсе Яңа елны өчәү каршыласак иде, дип теләгән ул.

– Миңа табиб бала туу вакытын 12 гыйнварда дип билгеләгән иде. Яңа ел төнендә бәби табармын дип башыма да китермәдем. Тик тулгагым иртәрәк башланып китте шул. Улыбыз безгә көтелмәгән бүләк ясады, – ди Гөлназ.

Яңа елда сабыйлары иң беренче булып туган гаиләләрне кайчак зур бүләкләр белән дә сөендерәләр. Шуны ишетептер инде, Гөлназдан да: «Сезгә бүләк бирмәделәрме?» – дип, кат-кат сораучылар бар икән. Юк, бернинди бүләк эләкмәгән. «Иң зур бүләк – улыбыз», – ди ул. Сабыйлары холкы белән әти-әнисенә охшаган: үзләре кебек тыныч.

Яңа ел төнендә сәгать 00.30да Чирмешән районында яшәүче Лилия Таҗиева белән Оганнес Мовсесянның дүртенче сабыйлары туган. Олысы Даутка – 16, Мәликәгә – 8, Эмильгә – 2 яшь тә 7 ай. Аларга хәзер энекәш – Давыдны алып кайтканнар. Оганнес – әрмән милләтеннән. Алар төзелештә танышкан. Икесе дә штукатур-маляр булып эшли.

– Районда бала тудыру йорты ябылды. Безгә 80 чакрым ераклыктагы Әлмәткә барырга кирәк. Юлда бәбиләү куркыта. Шуңа күрә берничә көн элек үк шәһәрдә яшәүче сеңелләргә киткән идем. Табиб, гыйнвар башында гына табасың, диде. Шуңа күрә Яңа ел төнендә үк бәби көтмәгән идек. Бергәләп табын әзерләдек. Сәгать телләре 12не сукканны көткәндә, тулгагым башланып китмәсенме?! Ирем тизрәк хастаханәгә илтте, – ди 35 яшьлек Лилия. – Бала табарга курыкмаска, алдан психологик яктан үзеңне әзерләргә кирәк. Дүртенче көндә өйгә кайттым инде.

Лениногорскида яшәүче Гөлназ да сабыен Әлмәткә кунакка барган җирдә тапкан.

– Бүген ирем тәүлек буе эштә, өйдә үзем генә шул. Көн-төн бала карыйм, шуңа күрә сөйләшергә вакыт юк, – диде Гөлназ. – 31 декабрь көнне иртүк тулгагым башланган иде. Ялган гына, ахры, дип уйладым. Ирем эштә булгач, әтием һәм сеңлем янына кунакка Яңа ел каршыларга Әлмәткә киттем. Кичке сәгать 6лар тирәсендә бәлеш ашарга җыенганда, мине бала тудыру йортына илттеләр. Анда, өч көн эчендә табасың, диделәр. Ә мин Дамирымны 1 гыйнварда көндезге 1 сәгать 35 минутта таптым.

Лениногорск бала тудыру йортында исә бу елның беренче сабые 1 гыйнварда иртәнге 8 сәгать 37 минутта дөньяга килгән. Сәлаховлар гаиләсендә 3 килолы кызчык туган.

Буа районы хастаханәсенең акушерлык бүлеге мөдире Миләүшә Җәләлетдинова әйтүенчә, быел Яңа ел төнендә бәби табучы юк. Әлегә гыйнварда 4 бала туган. Малайлар күбрәк.

– Узган ел бездә, иң соңгы булып, 25 декабрьдә кыз бала дөньяга килде. Бу елны малайлардан башладык. 2 гыйнварда беренче булып ир бала туды. Безнең эш бәйрәмгә карамый. Әниләр һәм бәбиләр исән-сау булсын. Никадәр генә арыган булсак та, бала кычкырып җибәрүгә, талчыгулар юкка чыга. Әнисе күкрәгенә куйгач, ул бала сөтен дә имеп тә куйса… Әниләр елап, ә без сөенечтән көлеп җибәрәбез. Бала тудыру йортында эшкә җаны-тәне белән бирелгән акушерлар гына эшли ала, – ди Миләүшә Җәләлетдинова.

Сәрия МИФТАХОВА

ТУГАН ЯК ҖЫЛЫСЫ

Ярдәм янәшә

Республикада махсус хәрби операциягә киткән егетләргә кирәк-яраклар җыю дәвам итә. Кем ничек булдыра ала, шулай үзеннән өлеш кертеп, солдатларга ярдәм итәргә тырыша. Йокы капчыклары да тектеләр, кием-салым да юнәттеләр, маскировка челтәре дә үреп җибәрделәр. Кыскасы, хәрбиләргә оекбаштан алып хәрби машинага кадәр озаталар. Барысында бер генә теләк: егетләр җиңү белән кайтсын.

Питрәч районының Керәшен Сәрдәсендә яшәүчеләр, якташларына җибәрү өчен, хәрби машина сатып алган. Әлегә 250 мең сумга алган «УАЗ»ны ремонтлыйлар икән. Аннары машинаны хәрби операциядәге якташларына җибәрәчәкләр.

Минзәләдә исә, Татар Мөшегесе авылы эшмәкәре Айдар Исламов егетләргә 400 банка тушенка җибәргән.

– Эшмәкәрлек белән 2015 елдан башлап шөгыльләнәм, үземнең мал чалу цехым бар. Симертү өчен 80 баш үгез асрыйм. Ил сакчыларыбыз өчен күчтәнәч итеп карабодай, дөге, борчак, борай белән тушенка алып килдем, – ди ул.

Мондый чакта нинди генә ярдәмнең дә артыгы юк. Иң мөһиме – читтә калмау. Азнакай районының Актүбә бистәсендә мөмкинлеге чикләнгән кешеләр концерт куеп, җыелган акчага солдатларга кирәк-ярак сатып алалар икән. «Җырлы язмышлар» төркемен Ләйлә Кәрамова җитәкли. Алар инде республикада өлешчә мобилизация башлангач та, «Казан ЭКСПО»га 5 тапкыр барып, чыгыш ясаганнар. Егетләргә Азнакай пешекчеләре тәмле бәлешләр пешереп җибәргән.

Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илһам Гайнетдинов та район халкының бердәмлегенә шаккаткан. Өлешчә мобилизация башлану бөтен кешене берләштергән.

– Райондагы оешма җитәкчеләре, эшмәкәрләр, гади халык ярдәме белән 10 миллион сум акча җыелды. Бу акчага үз районыбыз егетләренә кирәк-яраклар алдык, – ди ул.

Менделеевск районында яшәүчеләр дә бу көннәрдә хәрби операциядәге егетләргә 31 маскировка челтәре җибәргән.

– Ярдәм итүчеләргә рәхмәт! Район хакимияте челтәрләр өчен тукыма һәм окоп шәмнәре өчен балавыз сатып алуны дәвам иттерәчәк, – дип белдергән социаль челтәрләрнең берсендә район башлыгы Радмир Беляев.

Татарстанда өлешчә мобилизацияләнүчеләргә «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» иҗтимагый оешмасы адреслы ярдәм күрсәтә. Алар һәр кешегә кирәкле әйберләр җыялар. Соңгы тапкыр гуманитар ярдәмне 2022 елның декабрь ахырында Лисичанскига җибәргәннәр.

– Яңа ел алдыннан 2 мең балага Кыш бабай бүләге һәм егетләребезгә кирәк-яраклар җибәрдек. Узган ел барлыгы 800 тонна гуманитар ярдәм юлладык. Бу атнада хәрбиләргә тагын ярдәм китәчәк. Бу юлы төзелеш инструментлары, җылыту пушкалары, киемнәр, азык-төлек, дарулар һәм медицина кирәк-яраклары җибәреләчәк. Гыйнвар ахырында исә «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге белән берлектә Лисичанскига тагын гуманитар ярдәм озатырга ниятлибез, – ди «Ярдәм янәшә!» хәрәкәте координаторы Тимур Сафин.

Әлеге хәрәкәт хәрби операциядәгеләрнең гаиләләрен дә ташламый. Аларга һәр яклап ярдәм күрсәтәләр. Кайчак бу гаиләләр үзләренә нинди ярдәм тиешлеген, аны алыр өчен кая барасын да белмиләр икән. Тимур Сафин әйтүенчә, һәр кеше белән аерым сөйләшәләр, аны ниләр борчыганын ачыклыйлар. Иң мөһиме – ярдәм итәргә ашыгалар. Кемгәдер бер җылы сүз җитә, кемгәдер гаиләләргә хуҗалык эшләрендә дә булышалар. Психологик ярдәмнең дә артыгы юк. Узган ел «Ярдәм янәшә!» хәрәкәтенең «кайнар линия»сенә 40 мең тапкыр шалтыратканнар. 2500 кешегә матди һәм психологик ярдәм күрсәтелгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ШАКИРОВ МИНСӘГЫЙТ ЗАКИР УЛЫ

(01.06.1948 – 15.01.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Татарстан Республикасы атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советының элекке рәисе Минсәгыйт Закир улы Шакиров 15 гыйнвар көнне 75 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Минсәгыйт Шакиров 1948 елның 1 июнендә Татарстан АССРның Беренче Май районы (хәзерге Чирмешән муниципаль районы) Лашман авылында дөньяга килә. 1976 елда – М.Горький исемендәге Казан авыл хуҗалыгы институтын, 1983 елда Саратов югары партия мәктәбен тәмамлый.

Минсәгыйт Закир улы хезмәт эшчәнлеген 1966 елда «Дуслык» газетасының әдәби хезмәткәре буларак башлап җибәрә. 1968–1978 елларда Чирмешән районы Чишмә машина-мелиорация станциясендә өлкән белгеч, баш инженер, ПМК-17 җитәкчесе булып эшли. 1978 елдан Чирмешән һәм Яңа Чишмә районнары җирле, партия органнарында җаваплы вазыйфаларны били.

Минсәгыйт Шакиров, 1988 елдан башлап, 22 ел дәвамында Чирмешән районына җитәкчелек итте: КПСС район комитеты беренче секретаре, халык депутатларының район советы рәисе, район хакимияте башлыгы булды. Ул гаять катлаулы елларда районның икътисадый һәм социаль базасын саклап кына калмыйча, аны үстерүгә дә иреште. Торак фонды, социаль һәм юл инфраструктурасы объектлары төзелде, авыл хуҗалыгы өлкәсе ныгыды.

Минсәгыйт Шакиров XII чакырылыш Татарстан АССР Югары Советы, I һәм II чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты булды.

2006 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советының беренче съезды делегатлары Минсәгыйт Шакировны совет рәисе итеп сайлады. Ул 10 ел дәвамында Татарстанның муниципаль бергәлегенә җитәкчелек итеп, җирле үзидарәне булдыру һәм үстерүгә, муниципаль берәмлекләрнең икътисадый, хокукый һәм территориаль нигезләрен булдыруга зур өлеш кертте. Минсәгыйт Закир улы ассоциациянең республика законнар чыгару һәм башкарма хакимияте органнары белән нәтиҗәле төстә берлектә эшләвен булдырды, гомумроссия муниципаль берәмлекләр берләшмәсе белән хезмәттәшлекне җайга салды. Минсәгыйт Шакировның төп тырышлыгы халык мәнфәгатьләрендә муниципаль берәмлекләр проблемаларын хәл кылуга ярдәм итүгә юнәлдерелде. Ул шулай ук территорияләрнең, аеруча авыл җирлекләре территорияләрен социаль-икътисадый яктан үстерү программаларын тормышка ашыруга, шулай ук муниципалитетлар арасындагы хезмәттәшлекне ныгытуга зур игътибар бирде. Аның җитәкчелегендә Татарстан муниципаль берәмлекләре советы эшчәнлеге күп тапкыр Россия Федерациясендә иң яхшысы дип танылды.

Минсәгыйт Шакировның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм профессиональ казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Болар – Дуслык, Почет, «Татарстан Республикасы алдындагы хезмәтләре өчен» орденнары, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Фидакарь хезмәт өчен», «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылуга 100 ел» медальләре, Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы, Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәте.

Минсәгыйт Шакиров үзен югары квалификацияле гадел җитәкче, талантлы оештыручы буларак танытты. Иҗтимагый бурычына тугрылыгы һәм хезмәт сөючәнлеге, кешеләргә карата игътибарлы мөгамәләсе аңа зур абруй-хөрмәт китерде.

Минсәгыйт Закир улы Шакировның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН,
А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, М.А. ҖӘББАРОВ, Ә.С. ГОБӘЙДУЛЛИН,
И.Р. МЕТШИН, Н.Г. МӘҺДИЕВ, В.М. КОЗЛОВ, Р.Т. АЙБАТОВ,
Х.Г. ИШТИРӘКОВ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, XII чакырылыш (1990–1995 елларда) Татарстан Республикасы Югары Советы депутаты, I (1995–1999) һәм II (1999–2004) чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы рәисе (2010–2017)

ШАКИРОВ Минсәгыйт Закир улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советының элекке рәисе

Минсәгыйт Закир улы ШАКИРОВның

вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, Минсәгыйт Закир улы Шакиров кинәт вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Ташып торган көч-куәте, кешелеклелеге белән хезмәттәшләре, аны белүче барча кеше арасында зур абруй-хөрмәт яулады. Ул бөтен гомерен республикага хезмәт итүгә багышлады. Минсәгыйт Закир улы 27 ел дәвамында, шуның 19 елын – район хакимияте башлыгы вазыйфасында, туып-үскән Чирмешән районына хезмәт итте. 2006 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советының беренче рәисе итеп сайланды. Шушы еллар эчендә ул җирле үзидарә органнарын бергә туплауга иреште, җирле үзидарәнең күп кенә мәсьәләләрен хәл кылуга үзеннән зур өлеш кертте.

Аның мәңгелеккә китүе – зур югалту. Бу авыр көннәрдә сабырлык, ныклык телибез.

Ихтирам белән, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллин

«Чирмешән якташлыгы җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы исеменнән, Минсәгыйт Закир улы Шакиров вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклашабыз.

Ул Лашман авылында туып-үсте. Гомеренең күпчелек өлеше туып-үскән районына бәйле булды. Аны Чирмешәндә генә түгел, бөтен республикада яхшы беләләр. Оптимистлык рухына, куелган максатка ирешү омтылышына ия булуы, үз эшенең остасына әйләнүе аны әнә шундый биеклеккә күтәрде.

Минсәгыйт Шакиров республиканың ватанпәрвәре иде. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы рәисе булып торды, Чирмешән якташлыгы эшчәнлегендә актив катнашты.

Мәрхүмнең туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклашабыз. Аның тормыш юлы – безнең өчен үрнәк. Авыр туфрагы җиңел, урыны оҗмахта булсын.

Ихтирам белән, «Чирмешән якташлыгы җәмгыяте» рәисе Раушания Кыяметдин кызы Сәүбәнова

Татарстан агросәнәгате ветераннар советы президиумы, шәхсән Советның рәисе Марс Шәриф улы Алиев, заманында төрле җитәкче вазыйфаларда армый-талмый хезмәт куйган якты шәхес, республика үсеше өчен бинихая зур өлеш керткән дустыбыз, фикердәшебез

Минсәгыйт Закир улы ШАКИРОВ

вафат булу сәбәпле, туганнарының, якыннарының, кулга-кул тотынып, бер-берсен аңлап эшләгән хезмәттәшләренең авыр кайгысын уртаклаша.

Спас районының Иске Рәҗәп авыл жирлеге советы,

Минсәгыйт Закир улы ШАКИРОВ

вафат булу сәбәпле, аның гаиләсенең, туганнарының олы кайгысын уртаклаша.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республикада гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве системасын үстерүгә өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы урынбасары **Әхмәтҗанов** Ренат Харис улы, архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Архитектор Бакулин Герман Алексеевичның шәхси иҗат остаханәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Бакулин** Герман Алексеевич, илебез приборлар төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Җылылык-энергетика приборлары төзү һәм автоматлаштыру чаралары үзәк проектлау-конструкторлык бюросы» ябык акционер җәмгыяте генераль директоры **Бахтеев** Юрий Юрьевич, республиканың төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Саба проектлау остаханәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Галимов** Шәфкать Мөхәммәтзәки улы, һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм нәтиҗәле хезмәтләре өчен «ЭНКА Иншаат ве Санайи А.Ш.» тәрҗемәчесе **Гаффарова** Ләйлә Габделәхәт кызы, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты кадрлар һәм юридик эш бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Максимова** Людмила Анатольевна, халыкны социаль яклау системасын камилләштерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының эш белән тәэмин итүдә актив сәясәт чараларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы **Кибардина** Елена Михайловна, мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм республикада һөнәр берлекләре хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре һөнәр берлегенең Татарстандагы Мамадыш территориаль оешмасы рәисе **Саттаров** Зөфәр Рәүф улы, күпьеллык намуслы хезмәте, элемтә чараларын үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе өчен «Таттелеком» гавами акционер җәмгыятенең Казан электр элемтәсе идарәсе үсеш һәм төзелеш үзәген килештерү төркеме әйдәүче инженеры **Хөсәенов** Илдар Гомәр улы, законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итүгә, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Буа шәһәр суды рәисе **Шамионов** Рафаэль Рәҗәтдин улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Сәйдәшев исемендәге авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Габидуллин** Ринат Фәрит улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Гатауллин** Дилүс Гаскәр улына, «Чынлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 1 номерлы товарлыклы-сөтчелек фермасы мөдире (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Сөләйманов** Айрат Вазыйх улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Фикер

Багананың урыны кайда?

Былтыргы елак көзнең үтә дә сирәк булган кояшлы көнендә бер авылга барырга туры килде. Булачак язмам геройларының кайда яшәгәнен белмим. Шуңа күрә авылда беренче очраган кешедән сорарга дип ниятләп барам. Әнә ерак түгел бер йортта берничә кеше мәш килә. Урам буендагы коймаларын яңарталар икән. Таякка таянган бер бабай, урта яшьләрдәге ир-ат һәм ике үсмер малайны күреп, сөенеп куйдым.

Барып җитеп, сәлам бирергә дип авыз ачуым булды, таяклы бабаем бөтен дөньяга ишетелерлек итеп кычкырып җибәрде:

– Багана чокырын анда казыма дип әйтәм, багананың урыны гомергә менә монда булды, менә монда казы!

Әллә мине күреп, әллә шулай гадәтләнгәнгә, 40–45 яшьләрдәге ир-ат – күрәсең, кычкыручы бабайның улы – берни дәшмәде. Киресенчә, читенсенеп, башын түбән иде. Ә бабаеңа чит кеше нипачум, ул «киребеткән» улын, үсеп килүче, инде буйга үзеннән озын ике оныгы каршында тиргәвен дәвам итеп калды. Мин исә, телсез калып, сәлам дә бирмәдем, сорашмадым да – юлымны дәвам иттердем.

40 яшькә җитеп, багана чокыры урынын билгеләргә дә хокукы булмаган ир-атны кызганыргамы, тиргәргәме – аптырадым. Әллә инде кулының көче китсә дә, улына түгел, инде оныкларына юл бирергә акылы, хикмәте җитмәгән бабайны җәлләргәме, диеп уйландым. Өлкән кешене инде орышудан мәгънә юк, бу яшькә кадәр шушы гади бер хакыйкатьне аңлый алмаган икән, инде «поезд» киткән… Миңа калса, урта буын – әти кеше үзе дә улларына нәрсәдер бирергә соңга калган. Дөресрәге, аның моңа хокукы да юк бугай…

Кызганычка, арабызда әле: «Мин мәңге яшәмәм, эшләгәнең минем өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен», – дип, баласын шушы нигездә үзеннән соң да тормыш гөрләп дәвам итәрлек итеп, сабый чактан һәртөрле эшкә сабыр гына өйрәтеп үстерә белмәүчеләр дә бар. Бу кадәресе әти кешеләргә генә түгел, әниләргә, улларга-кызларга да бердәй кагыла. Кулы мең дә бер һөнәр белгән әтиләрнең утызга җитеп тә бер корал тота белмәгән уллар үстерүеннән, баласына өйрәтеп азапланганчы, үзе ялт иттереп эшләп куючы әниләрдән әллә ни мәгънә юктыр. Үзе эш рәтен белмәгән әти-әниләр алга таба баласына нәрсә өйрәтер, аңа нинди киңәш бирер икән соң?

Бер уйландыра торган хәл турында сөйләгәннәр иде. Күрәсең, үзе дә шундый тәрбия алып үскән әти кеше үсмер улына эш коралларын тотарга, эшләп карарга рөхсәт бирмәгән. «Үзенә корал алсын, бөтен коралларны бозып бетерә», – дигән. Бу, мөгаен, ир баланың күңеленә мәңгелеккә сеңеп калгандыр, үзе эшләп тапкан беренче акчасына ук ул әтисенә берничә төрле, заманча кораллар бүләк иткән. Әти кеше моның үзенең күп еллар элек әйткән сүзләренә җавап икәнен аңлый да белмәгәндер, бәлки, әмма Аллаһы Тәгалә улын аннан күпкә зирәгрәк акыл белән бүләкләгән дигән фикергә киләсең.

Шушы хәлне язганда, хәтеремдә үзебездә булган бер истәлек яңарды. Себердәге апамның ике улы җәйге каникулларда бездә тора, алар янына еш кына Балтачтагы апамның улы да кайта иде. Тыңлаусыз булсалар, өч үсмер малай белән әнигә җиңел булмас иде. Әмма, шөкер, алар бик тәртипле булды. Барыбер күздән югалтып булмый, балалар өчен әти-әниләре алдында җавап та бирәсе бар бит әле. Әни бер елны аларга кызыклы шөгыль тапты. «Чебиләргә-тавыкларга азык бирергә тагарагым тузды, әйдә, ясап бирегез әле», – дип, өч малайга кечкенә пычкы, иске кадаклар (турайтып көннәре үтсенгә), чүкеч, калдык-постык такталар тоттырды. Әй тырышып ясады алар бу тагаракларны. Әни белән без мактап торабыз. Ясаган берсен келәткә кертеп куя баралар. Чалыш-чолыш булсалар да, без дә аларны чыгарып атмадык. Ни дисәң дә, балалар тырышып ясаган бит. «Әтиләре бу балаларның пычкы-чүкеч белән мәш килгәнен күрсә, нәрсә дияр иде икән?» – дип көлешә идек шул чакта. Шөкер, өч энекәш тә кул эшләренә оста булып үстеләр, нәрсәгә тотынсалар, шуны булдыралар. Бәлки, безнең тагаракларның да өлеше бардыр әле, дип сөенәм.

Урта яшьтәге улына багана чокырын ышанып тапшыра алмаган әти кеше язмышы кайта-кайта уйландырды мине. Ә бит балага әле сабый чакта ук әти-әнинең ышануы бик кирәк, бала өчен бик мөһим аны тою. Үзебезнең балалар кечерәк чакта көтүгә чыгарга атлыгып торалар иде. Әтиләре машинаны аларга калдырып китә. Улыбыз бик кечкенәдән машина йөртергә өйрәнде. Ул болында машина йөртә, апасы аның янына утырып йөри, мин аларны саклыйм… «Әти безгә ышана, име, машинасын да калдырып китә», – дигән иде шул чакта улым. Аннан берничә ел үткәч, өйдәге бердәнбер ноутбук нәрсәгәдер киреләнә башлады. Аннан алдарак шулай көйсезләнгәч, апамның информатика укытучы кияве Наил карап, көйләп биргән иде. Наил җизнәсе эшләгәнне бик игътибар белән күзәтеп торган улым: «Әни, кая үзем төзәтеп бирәм», – ди. Күңелемдә мең дә бер шикле уй булса да, рөхсәт бирдем бит. Улым ноутбукның санын-санга аерып, сүтеп бетергәндә, җыя алырмы икән дип борчылсам да, сиздермәдем. Тәртипләп бирде бит балакай! Ул бер сөенсә, мин мең сөендем. Еллар үткәч тә улым: «Әни, син миңа шул вакытта ноутбугыңны да ышанып сүттерден бит», – дип искә алды.

Өлкәннәр белән яшьләр арасында каршылык гомер-гомергә булган анысы. Каршылык та түгел инде бу, заманга-чорга карап үзгәреш, фикерләр, карашлар төрлелегедер, бәлки. Өлкәннәр үзләренчә эшләргә, яшәргә ярата. Ә яшьләрнең – тормышка үз мөнәсәбәте, аларның үзгәртәсе, яңартасы, матурлыйсы килә. Өлкәннәр зирәк акыл белән яшьләргә вакытында юл бирмәсә, тормыш та чуала, алар еш кына үзләре дә кадерсезгә кала. Дөрес, үзең корган «калып»лардан баш тарту җиңел түгелдер. Тик тормыш бик тиз үзгәрә: безнең фикер-киңәшләр инде бүгенгегә яраклы түгел, тормышка мөнәсәбәтләребез дә башка. «Өлкән кеше» дигән дәрәҗәне онытып, багана чокыры белән дә ваклансак, көч-куәт бөтенләй беткәч, безнең урын кайда булыр?

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТАТАР ЯШӘГӘНДӘ, ӘЛФИЯ ДӘ ҮЛМӘС

Хәтер

15 гыйнварда татар халкының сөекле җырчысы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы, Тукай премиясе лауреаты Әлфия Авзалованың тууына 90 ел тулды. Легендабызның бакыйлыкка күчкәненә биш елдан артык вакыт узса да, ул әле дә арабызда кебек.

Әлфия пәрәмәчләре

15 гыйнварда Әлфия Авзалованың туган көне булса, 16 гыйнварда Илһам ага Шакировның арабыздан китүенә 4 ел булган икән. Кичә әлеге ике легенда җирләнгән Яңа Татар бистәсе зиратында җырчыларның каберенә чәчәк салдылар.

Әлфия Авзалова истәлегенә багышланган чаралар циклын апрель азагында зур концерт белән дәвам иттерергә ниятлиләр. Бу хакта аның кызы Зөлфия Нигъмәтҗанова-Авзалова сөйләде. Шулай ук яз көне Әлфия Авзалова исемендәге III Халыкара фестиваль-конкурска гаризалар кабул итә башлаячаклар. Конкурс үзе октябрьдә узачак. Моннан тыш, яздан башлап «Туган авылым» милли комплексында урнашкан Әлфия Авзалова исемендәге Үзәктә махсус экскурсияләр уздырырга телиләр.

– Экскурсия азагында кунакларны әнинең яратып пешерә торган пәрәмәчләре белән сыйларга җыенабыз. Алар гади пәрәмәчтән зурлыгы белән аерылып тора. Әни аларны һәрвакыт зур итеп пешерде. Ятим булгач, балачагында һәм яшьлек чорында еш кына тамагын туйдыра алмаган ул. Шуңа күрә үз гаиләсенә һәркем бер тапкыр ашауга тамагын туйдыра ала торган пәрәмәчләр пешергән, – ди җырчының кызы Зөлфия ханым.

2023 ел азагында исә легендар җырчы исемендәге фонд чираттагы проектын – Әлфия Авзаловага багышланган мюзикл-спектакль тәкъдим итәр дип көтелә.

– Әнинең репертуарыннан 20–30 җыр туплап, «Аксу» компаниясе белән караоке да чыгарырга ниятлибез. Шөкер, кайсы ишеккә шакысак та, кире какканнары юк. Беренче Президентыбыз Минтимер Шәрипович та, Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич та игътибарсыз калдырмыйлар. Хөкүмәт, Бөтендөнья татар конгрессы, филармония, Казан мэриясенең дә ярдәмен тоябыз. Аз булсалар да, меценатларыбыз бар. Фондка аларның ярдәме бик кирәк. Ничек тә туктап калмаска, эшебезне дәвам иттерергә иде. Әнинең исемен халык күңелендә яшәтәсе килә бит… – дип сөйләде безгә Зөлфия ханым.

Татарның хатын-кыз җаны

Татар яшәгәндә, үлмәс җырчы ул. Рабит Батулла якын дусты Әлфия Авзалованы шулай бәяләде.

– Әлфия Авзалованы оныттылар дип әйтеп булмый. Татар, рус, инглиз телләрендә зур-зур китаплары чыкты, үзе яшәгән йортта истәлек тактасы куелды, музее бар. Кызы – Зөлфиясе бик тырышып эшли. Әнисе өчен үлеп тора иде ул. Хәзер менә аның эшен дәвам иттерә. Әлфия апаны, Зөлфия булганда, халык онытмас. Хәер, татар яшәгәндә, Әлфия болай да онытылмас ул. Татар халкы яшәгәндә, Илһам да, Әлфия дә яшәр. Алар икесе дә – уникаль шәхесләр. Берсе – татарның хатын-кыз җаны, икенчесе – ир-ат җаны. 50 ел гомерен халыкка, татар җырына хезмәт итүгә багышлаган кешеләр. Ни генә булса да, җырлаудан туктамады алар. Икешәр ай гастрольләрдә йөргәндә салкын тидерсә дә, бер тапкыр да концертын өзгәне булмады Әлфия апаның. Үзен кызганмый иде. Бу – үзе батырлык.

«Әйбәт кенә, малакачкаем!»

Әлфия Авзалова турында хатирәләре белән аның якташы, журналист Эльмира апа Закирова да уртаклашты.

– Ничә яшьтә булганымны төгәл генә хәтерләмим. Әти белән каядыр баруыбыз иде. Юлыбызга Әлфия апа очрады. Әти шунда: «Ни хәл, Әлфия?» – димәсенме?! Шаккаттым. Әлфия апаның: «Әйбәт кенә, малакачкаем! Концертлар белән кайттык әле», – дигән сүзләреннән соң бу хис артты гына. Соңыннан әтидән: «Әллә син аны якыннан беләсеңме?» – дип сорадым. «Юк инде, болай гына эндәштем», – диде әти. Күптәнге танышын күргән кебек җавап бирүе генә дә ни тора бит Әлфия апаның!.. Тагын бер хатирәм 2005 нче елларга барып тоташа. Бер автобус халык – якташ язучылар, журналистлар, артистлар – Актаныш Сабан туена кайтабыз. Арада Әлфия апа да бар. Төрле кызыклар сөйли. Ялындырмый, җырлап та җибәрә. Баянчы Зиннур Гыйбадуллин үзе сизмәгәндә, портфеленә кирпечләр тутырып, юри авырайтуларын, бер фатирга урнашкач, карават астында утырган каз юрганын тартып төшергәнне, йөк машинасында авылга килеп төшкәч, чегәннәр дип кабул итүләрен мәзәк итеп сөйли. Эч катканчы көләбез. Аның белән озын юллар да кыска тоела. Иртәгә Сабан туе буласы көнне кич район мәдәният йортына җыелабыз. Талантлы балалар чыгышы, «Агыйдел» җырбию ансамбле концерты… Сәгать төнге унбердә затлы кунак – Әлфия Авзалова чыга сәхнәгә. Гадәттә, дәрәҗәле җырчыны аккорд рәвешендә иң ахырдан чыгаралар да шулай, концерт тәмамлана. «Концерт бетә дә инде», – дип өтәләнәм. Янәшәмдә төрле авылларның хуҗалык җитәкчеләре утыра иде. Минем сүзләрдән соң дәррәү көлеп җибәрделәр: «Нәмәдәй бетү?! Әле башлана гына!» – диләр. Һәм, чынлап та, Әлфия апа рәхәтләнеп, сәхнәдә килеш халык белән аралаша-аралаша, сөйли-сөйли җырлый – тәмам түгелә! Ә залдагылар таң атканчы тыңларга да риза!

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КӨТЕП АЛГАН ФӘРЕШТӘ

Язмыш

Тәкъдир дигәнгә ышанмый кара син! Яңа Чишмә районының Зирекле авылында яшәүче Зөмәрия Сәлимованың язмыш йомгакларын сүткәндә, бу фикер башка ничәмә ничә тапкыр килде икән! Бормалы-сырмалы, сынаулы көннәрдән соң очраклы гына рәвештә чын бәхетен тапкан гап-гади татар хатыны турында язмабыз.

Озак еллар Түбән Кама шәһәрендә яшәгән Зөмәрия ханым алты ел элек авылга кайтып төпләнә.

– Тормышымны үзгәртергә ниятем бар иде барлыкка, тик сукмаклар бөтенләй башка якка таба борылды. Түбән Камадан күченеп, башкалага якынлашмакчы идем мин. Төгәлрәге, Биектаудан фатир алып, ремонт ясый башлаган идем хәтта. Тик язмышның планнары башка булып чыкты, – дип бәян итә башлады ул гомер юлын. – Ирем Рифкать белән элеккеге хезмәттәшем таныштырды. Шулай итеп, берничә көн эчендә тормышым үзгәрде дә куйды. 45 яшьтә туйлар ясап, туй күлмәкләре киеп, моңа кадәр атамасын да ишетмәгән авылга килен булып төштем. Рифкать белән никах укытып, рәсми төстә язылыштык. Шунда ук аның фамилиясен дә алдым.

Бәлки, кайберәүләр, моның нәрсәсе бар инде, дияр. Тик бер-берсен табышканчы, кавышканчы Рифкать абыйның да, Зөмәрия апаның да гаилә тарихлары сикәлтәле, бормалы, каршылыклы булган.

– Татар хатыннарына хас булганча, ир белән тормыш авыр булса да, беренче иремнән аерылып китәргә батырчылык итмәдем. Парлы тормышта 22 ел узса да, бәхетле көннәремне хәтерләмим. Балаларымның әтисе – әфган сугышын кичергән кеше. Шуның белән күп нәрсә аңлашыла торгандыр, – диде Зөмәрия апа, артык тирәнгә китмичә генә. – Элеккеге ирем эшләргә яратмады, үзем өчәр эштә эшләдем, барысына да түздем, күрмәгән авырлык калмагандыр. Балалар үсеп җиткәч кенә юлларыбыз аерылды. Алар исә барысын да аңларлык яшьтә. «Әни, ник түзеп яшәдең? Ник баштан ук аерылышмадың?» – диләр.

Язмышның ачы камчысы ир сыртына да шактый гына төшкән булып чыкты.

– Рифкать белән кавышасы елны икебезнең дә тормышлар кисәк һәм бик нык үзгәргән булып чыкты. Ул елны без икебез дә бер ел эчендә утта да янганбыз, суга да кергәнбез. Соңыннан ирем: «Язмыш безгә шулкадәр сынаулар биреп, бер-беребезгә якынайткандыр, күрәсең», – диде. Ул дин юлына басты. Без Рифкать белән 6 ел бергә яшибез. Шул еллар эчендә яратып кабатлый торган бер җөмләсе бар: «Син – минем Аллаһы Тәгаләдән сорап алган фәрештәм». Чөнки беренче никахында ул да күпне күргән… Ә мине ул бик яхшы күңеле белән үзенә каратты. Җылы, матур сүзләрен кызганмый, бик ярдәмчел һәм мине бик нык хөрмәт итә. Ике як туганнарыбыз белән дә аралашып, кунакларга йөрешеп яшибез. Мин аңа бик рәхмәтле, – ди бүген матур итеп яшәүче Зөмәрия апа.

Ул чагында ирне генә түгел, әтиләре белән бергә яшәп калган ике баланы да бәрәкәтле тормышка кайтарырга туры килә Зөмәрия апага.

– Әни җылысын улым, кызым белән бергә иремнең малае һәм кызына да бүлеп бирдем, – ди ул. – Шулай итеп, икебезгә бергә дүрт балабыз бар. Башта балалар мине ничек кабул итәрләр икән, дигән курку булды, әлбәттә. Алар да җылыга, назга, игътибарга сусаган. Ләкин алар белән уртак тел таба алдым. Мин килгәндә, нәрсәнең нәрсә икәнен аңлый торган яшүсмерләр иде бит инде. «Әни» дип әйтмәсәләр дә, «апа» дип үлеп торалар. Әниләре күрше авылда яши. Аралашып, күрешкәләп торалар.

Инде ул килгәндә 5 нче сыйныфта укыган кызлары да үсеп буй җиткергән. Бүген ул педагогика институтының икенче курсында белем ала.

– Тәртипле, акыллы кыз тәрбияләдек дип куанып торабыз. Улыбыз мәктәптә 11 нче класста укый. Әтисе кебек яхшы күңелле бала. Минекеләр зурлар инде – 25 һәм 27 яшь, гаиләләре бар. Балаларыбыз абыйлы-сеңелле шикелле якын итешеп яшиләр. Бер-берсенә «апа», «абый» дип эндәшәләр. Әле менә күптән түгел генә кызыбызның никахы булды. Барыбызның да бер гаилә булуы шундый чакта аеруча нык күренә.

Моңа кадәр шәһәрдә яшәп, үз тормышын үзе җигелеп тарткан хатын авылда да югалып калмый. Йорт-җирләрен яхшырталар, абзарны мал-туар, кош-корт белән тутыралар.

– Авылда туган булсам да, соңгы 30 ел гомерем шәһәрдә узган иде. 22 ел тәрбияче булып эшләгән кеше бит мин. Тавык та асрап караганым юк иде. Рифкать белән танышканчы, бу районның барлыгын да белми идем. Зиреклегә кайтканда аның терлеге юк иде. Читкә йөреп эшләгәч, бозауларын бетерергә мәҗбүр булган. Монда килүгә, кош-кортлар, мал-туар алып җибәрдем. Үрдәк, бройлерларны инкубаторда үзем чыгарам. Йорт-җирне дә карарга, матурларга, тәртипкә китерергә туры килде. «Шәһәрдән авылга кайтып, дөнья көтеп ятуыңа үкенмисеңме?» – дип, еш сорыйлар. Үкенсәм, абзар тутырып мал-туар асрар идеммени? Тугыз баш терлегебез бар, дүрт сыер гына савам бит. Өч бакчабызга яшелчәләр утыртабыз, теплицаларыбыз бар. Әле тагын авылда бер йорт алып җибәрдем. Мин бервакытта да эштән курыкмадым. Авылны, аның кешеләрен иремә караганда да күбрәк беләм. Ирем – нефтьче, командировкаларга еш йөри. Ул булмаганда төп ярдәмчем – 11 нче сыйныфтагы улыбыз.

Тавык та чүпләп бетермәс йорт мәшәкатьләрен хәл итү белән бергә, дәүләт эшенә дә барасы бар бит әле. Монда да сыната торганнардан түгел Зөмәрия Сәлимова.

– Авылга балалар бакчасында эшләрмен дип кайткан идем. Тик район башлыгы бик тә нык клубка керүемне теләде. Шулай итеп, монда мөдир булып эшли башлавымны сизми дә калдым. Уң кулым Аяз белән күңелле эшлибез. Аена егермеләп чара уздырабыз, – диде ул.

Тик шулай да хатын-кыз өчен иң мөһиме – йорттагы иминлек. Бу яктан бүгенгесенә шөкер итеп туймаслык Зөмәрия апаның.

– Мин, ниһаять, бүген үземне бәхетле дип әйтә алам, – ди ул. – Безнең Рифкать белән хәтта уйларыбыз да уртак. Мин авыз ачканчы, ул минем фикерне әйтеп тә куя. Әйтик, икебез дә урман, табигать яратабыз. Кайвакыт мин эштән арып кайтып керәм, ул, күземә карап: «Әйдә, җыен, киттек», – ди дә урманга алып чыгып китә. Һәм чыннан да, аннан мин башка кеше булып кайтам. Күз карашыңнан да аңлый торган якын кешең белән гомер итү – зур бәхет.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5302 данә
Гомуми тираж – 15536 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 206

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+